ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.12.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3238**

Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү, торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелек) өлкәсендә, күпфатирлы йортларны төзү өчен кооператив әгъзаларын җәлеп итүгә бәйле рәвештә, 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын раслау турында

2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 27 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү, торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелек) өлкәсендә, күпфатирлы йортларны төзү өчен кооператив әгъзаларын җәлеп итүгә бәйле рәвештә, 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасын кушымта итеп бирелгән тәртиптә расларга һәм аны 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә (әлеге карарга кушымта).

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәге карарларының үз көчен югалтуын тану турында:

- 2018 елның 12 февраленнән «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын раслау турында» 292 номерлы;

– 2018 елның 18 декабрендәге «2019 - 2021 елларга Зеленодольск муниципаль районында күпфатирлы йортларны һәм (яисә) кучемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауның ведомство программасын раслау турында» 2629 номерлы;

- 2020 елның 18 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районында 2021 елга һәм 2022-2023 елларга күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка кучемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын раслау турында» 2494 номерлы.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Расланган
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының

16.12.2021ел № 3238

**Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү, торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелек) өлкәсендә, күпфатирлы йортларны төзү өчен кооператив әгъзаларын җәлеп итүгә бәйле рәвештә, 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы**

## 1. Профилактика программасын эшләү өчен нигезләр.

Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү, торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелек) өлкәсендә, күпфатирлы йортларны төзү өчен кооператив әгъзаларын җәлеп итүгә бәйле рәвештә, 2022 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы (алга таба-Профилактика программасы түбәндәгеләр нигезендә эшләнгән:

- «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 ел, №248-ФЗ Федераль законның 44 статьясы (алга таба - 248-ФЗ номерлы Федераль закон).

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелек) турында нигезләмәне раслау хакында» 02.10.2021 ел, №944 карары.

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларын җәлеп итүгә бәйле рәвештә торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелек) турында нигезләмәне раслау хакында» 30.09.2021 ел, №938 карары.

## 2. Тикшерү төрен гамәлгә ашыруның агымдагы торышын анализлау, тикшерү (күзәтчелек) органының агымдагы һәм профилактик эшчәнлеген тасвирлау, профилактикалау программасы хәл итүгә юнәлтелгән проблемаларны характеристикалау

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру, шулай ук күпфатирлы йортларны төзү өчен кооперативлар әгъзаларын җәлеп итүгә бәйле, торак - төзелеш кооперативларының эшчәнлеген (алга таба-региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген)) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

2004 елның 30 декабрендәге «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия

Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең аның нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында билгеләнгән, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар, шул исәптән төзүчеләр, аларның вазыйфаи затлары, шулай ук кооператив әгъзаларының күпфатирлы йортларны төзү өчен акчаларын җәлеп итүче торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлешендә, аннан соң күпфатирлы йортларны карап тотудан тыш, һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне (алга таба - мәҗбүри таләпләр) үтәү региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып тора.

Башкарма комитет тарафыннан 2019-2020 елларда оештырылган профилактик эш кысаларында, өлешле төзү өлкәсендә закон таләпләрен аңлату буенча тикшерелгән субъектлар өчен, гражданнарның һәм контрольдә тотылырга тиешле субъектларның шәхси кабул итүләре, хатлар, шулай ук электрон почта, телефон шалтыратулары форматында, 100дән артык консультация һәм чара үткәрелде.

2019 елда төзүчеләрнең эшчәнлегенә карата планнан тыш 5 тикшерү үткәрелде. Тикшерү нәтиҗәләре буенча өлешле төзү өлкәсендә гамәлдәге законнарны бозуның 14 очрагы ачыкланды, 5 тикшерү акты төзелде, 2 күрсәтмә төзелде. Өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче төзүчеләрнең эшчәнлеген тикшерү вакытында ачыкланган бозулар буенча материаллар прокуратурага җибәрелде.

2020 елда «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль законның 6 ст.таләпләре , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре һәм дәүләт контроле (күзәтчелеген) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләренең 7 пунктына үзгәреш кертү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 438 номерлы карары нигезендә, өлешле төзүдә катнашу турындагы законнар таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга планнан тыш тикшерүләр үткәрелмәгән.

Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында төзүчеләрне һәм алар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган төзелеш проектларын проект декларацияләрендә бастырыла торган мәгълүмат базасында, өлешләп төзү буенча квартал саен хисап бирү, шулай ук торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан (ЕИСЖС) алына торган белешмәләрне дистанцион бәяләү буенча эш оештырылды.

Өлешле төзү өлкәсендә законнарны бозуны профилактикалау программасын гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында мәгълүмати сайтында ( http://zelenodolsk.tatarstan.ru) тиешле норматив хокукый актларның текстлары (текстларына сылтама) белән, өлешле төзү өлкәсендәге законнарның үтәлешен күзәтү предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яисә аларның өлешләре исемлеген күрсәтеп мәгълүмат һәм башка мәгълүмат урнаштырылган.

Законда саклана торган кыйммәтләр - күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өчен гражданнарның һәм

юридик затларның акчаларын җәлеп итүгә һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның күпфатирлы йортта һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларында гомуми өлешле милек хокукына һәм гомуми өлешле мөлкәткә хокукы барлыкка килүгә бәйле мөнәсәбәтләр, шулай ук өлешләп төзүдә катнашучыларның хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен һәм мөлкәтен яклау гарантияләрен билгеләү; күпфатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә, шулай ук торак - төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеше һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясыннан тыш.

Саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычын киметү хисабына тәэмин ителергә мөмкин:

1. Контрольдә тотылучы затларның мәҗбүри таләпләр турында, кабул ителгән һәм әзерләнә торган үзгәрешләр турында, контроль күзәтчелек чараларын уздыру тәртибе турында, контроль (күзәтчелек) объектлары хокуклары турында хәбәрдарлыгы.

2. Аларны бертөсле аңлатуны тәэмин итүче мәҗбүри таләпләрне куллану буенча аңлатмалар бирү.

3. Күзәтчелек объектларын контроль күзәтү органы белән даими хезмәттәшлеккә җәлеп итү.

Программаны үтәү өчен вазыйфаи затлар:

| | |
|---|---|
| программа җитәкчесе | Ганиев Ильяс Рәсим улы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, (84371) 4-05-76, Sovet.Zmr@tatar.ru |
| программаның координаторы | Хәбибуллин Зөлфәт Флун улы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, (84371) 5-37-99, Zulfat.Habibullin@tatar.ru |

## 3. Зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасын гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын кисәтү түбәндәге төп максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

1) контрольлек итүче затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намус белән үтәүне стимуллаштыру;

2) мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яки) законда саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүгә китерә торган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

3) мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлылыкны арттыру;

4) мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә зыян китерү куркынычын булдырмау һәм зарар күләмен киметү ;

5) контроль объектларында социаль җаваплы, намуслы хокукый тәртип модельләрен булдыру;

6) мәҗбүри таләпләрне контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан куллану практикасының бердәмлеген тәэмин итү.

Башкарма комитет тарафыннан профилактик чаралар үткәрү түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

1) өлешләп төзү өлкәсендә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләргә һәм шартларны ачыклау, аларның барлыкка килү куркынычларын киметү;;

2) «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми

сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) мәҗбүри таләпләрне актуаль хәлдә тоту, аларның үтәлешен бәяләү региональ дәүләт контроле (күзәтчелек) предметы булып тора;

3) контрольдә тотылучы затлар белән үзара хезмәттәшлекнең яңа чараларын һәм методларын куллану;

4) контрольдә тотылучы затларның хокукый грамоталылыгы дәрәҗәсен күтәрү һәм мәҗбүри таләпләрне бердәм аңлауны формалаштыру.

## 3. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү срогы (периоды)

| № т/б | Чара атамасы | Җаваплы башкаручы | Көтелгән нәтиҗә | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Мәҗбүри булган документларны (белешмәләрне) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru урнаштырып мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча контрольлек итүче затларга хәбәр итү :<br>- өлешле төзү өлкәсендәге законнарның үтәлешен күзәтү предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар яисә аларның өлешләре исемлеге.<br>- дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны җайга салучы норматив хокукый актларның текстлары.<br>- дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны җайга салучы норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр.<br>- «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында»31.07.2020 ел, №247-ФЗ Федераль закон нигезендә эшләнгән һәм расланган мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча җитәкчелек итү.<br>- мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге, контроль объектларын риск категорияләренә кертү тәртибе.<br>- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген), торак - төзелеш кооперативларының 2022 елга күпфатирлы йортларны төзү өчен | Башкарма комитетның вазыйфаи затлары | Контрольд ә тотылучы затларның мәҗбүри таләпләр турында мәгълүма тлылыгын арттыру | 01.01.2022 - 31.12.2022 , норматив-хокукый актларга үзгәрешлә р кертү буенча |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кооперативларның чараларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүне (зарарны) профилактикалау программасы.<br>- контроль (күзәтчелек) органы контрольдә тотучы заттан соратып ала торган белешмәләрнең тулы исемлеге.<br>- мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча консультация алу ысуллары турында белешмәләр.<br>- Башкарма комитет карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирү тәртибе турында белешмәләр;<br>- Башкарма комитетның хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад.<br>- күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге), торак - төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзү эшчәнлегенә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында доклад.<br>- Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда һәм (яисә) зыян китерү куркынычларын профилактикалау программаларында каралган башка белешмәләр | | | |
| 2. | Күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешле төзү мәсьәләләре буенча телефон элемтәсе, электрон почта, видео - конференц - элемтә, язмача рәсми мөрәҗәгать алганда, шулай ук профилактик чара, контроль (күзәтчелек) чаралары уздыру барышында контрольлек итүче затларга консультация бирү | Башкарма комитетның вазыйфаи затлары | Контрольдә тотылучы затларның мәҗбүри таләпләр турында мәгълүматлылыгын арттыру | ел дәвамында, контрольдә тотылучы затлардан мөрәҗәгатьләр керү буенча |
| 3. | Өлешле төзелеш өлкәсендәге законнарның үтәлешен күзәтүне гамәлгә ашыру хокукыннан файдалану практикасын Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru урнаштырып гомумиләштерү | Башкарма комитетның вазыйфаи затлары | Контрольдә тотылучы затларның мәҗбүри таләпләр турында мәгълүма | Елга бер тапкыр, хисаптан соң килүче елның 15 мартыннан да соңга |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | тлылыгын арттыру | калмыйча |
| 4. | Контрольдә тотылучы затның эшчәнлек алып бару урыны буенча йә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән профилактик визитны гамәлгә ашыру | Башкарма комитетның вазыйфаи затлары | Контрольдә тотылучы затларның мәҗбүри таләпләр турында мәгълуматлылыгын арттыру | Башкарма комитетка өлешле төзүдә катнашуның беренче килешүен теркәү турында мәгълүмат кергәннән соң бер ел дәвамында |
| 5. | Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү | Башкарма комитетның вазыйфаи затлары | Мәҗбүри таләпләрне бозуларны булдырмау | ел дәвамында, кирәк булганда |

## 4. Зыян китерү куркынычын профилактикалау программасының нәтиҗәлелеге һәм эффективлык күрсәткечләре

Профилактик материалларның эффективтивлыгын һәм нәтиҗәлелеген бәяләүнең төп механизмы булып түбәндәгеләр тора:

- контрольдә тотылучы затларның мәҗбүри таләпләр турында, контроль - күзәтчелек чараларын үткәрү тәртибе турында, контроль - күзәтчелек чаралары барышында контрольдә тотучы затларның хокуклары турында мәгълүматлылык дәрәҗәсен күтәрү;
- контрольлек итүче затлар тарафыннан җибәрелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу санын киметү.